СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

29.04.2017 | с. Введенская Слобода | №30-134

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетының 2017 елның 1 кварталында үтәлеше турында

Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д. В. Морозовның Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетының 2017 елның 1 кварталында үтәлеше турында хисабын тыңлап һәм фикер алышып,

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетының 2017 елның 1 кварталында үтәлеше турындагы хисапны расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д. В. Морозов

Югары Ослан муниципаль
районы Введенский Бистәсе
авыл җирлеге Советының 2017
елның 29 апреленнән № 30-134
карарына
1 номерлы кушымта

«Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең 2017 елның 1 кварталы өчен бюджет үтәлеше турында хисап»

Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетын 2017 елда үтәү «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны алып бару һәм гамәлгә ашыру шартларында гамәлгә ашырыла.

Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджеты, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп, керемнәр буенча 12792,1 мең сум күләмендә расланган,

Авыл җирлеге бюджеты 01.03.2017 елга керем өлеше буенча 13900,2 мең сум күләмендә үтәлгән, 109% ка үтәлгән (план - 12792,1).

Җирлек бюджеты керемнәренең төп өлеше түбәндәге салымнар хисабына формалашкан:

- физик затлар керемнәренә салым - 62 %ка башкарылган (план 337,9 мең сум булганда 208,7 мең сум күләмендә башкарылган);
- физик затлар мөлкәтенә салым - 5% ка гына башкарылган (план 423,5 мең сум булганда 19,2 мең сум);
- җир салымы - 115%ка үтәлгән - 13653,2 мең сум;
- мөлкәтне арендага бирүдән кергән табыш – 1,2 мең сум;
- түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керем - 17,8 мең сум;

Чыгымнар өлеше план буенча 12844,6 мең сум күләмендә башкарылган - 3067,1 мең сум яисә планлы билгеләнештән 24% ка.

Акча тотылды:
Идарә - 213,0 мең сум. Мәдәният - 144,6 мең сум, урамнарны яктыртуга - 287,8 мең сум, юлларны карап тотуга - 227,9 мең сум, су суыртуга - 304,3 мең сум.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В.Морозов